Безнен белән бер дулкында бул!

Май, 2025

# Чишмә башы

**Җир йөзендә тынычлык, дуслык,мәрхәмәтлелек,гаделлек булсын!**




*1 Май – илебез байлыгын булдыруда хезмәт иткән бөтен кешеләр бәйрәме. Көн саен үзенең хезмәте белән Ватанын һәм гаиләсен чәчәк аттыручы бөтен халык бәйрәме.*

*1 май чын-чынлап яз килүен белдерә. Нәкъ менә бу айда алмагачлар, шомыртлар ап-ак чәчкәгә күмелә. Бар җиһан гүя әкияти дөньяны хәтерләтә.*
*Барыгызны да яшел чирәмнәре шытып чыккан, каеннары яфрак ярган яз бәйрәме белән котлыйбыз. Яз сулышы күңелегезгә нур өстәсен. Бәхет кояшы көннән-көн яктыра барсын, йөрәгегез хискә тулсын, һәрвакыт яшь булсын. Гомерегез дә яз көне кебек якты, кояшлы, аяз күкле, нурлы булсын.*

## *Ә сез 1 май бәйрәме тарихын беләсезме?*

*Әмма эчкәрәк кереп китсәк, аның тарихы бөтенләй башка, әлбәттә. Ул XIX гасыр ахырында эшчеләрнең үз хокуклары өчен көрәше нәтиҗәсендә барлыкка килә. 1886 елда Чикаго шәһәрендә эшчеләр эш көнен 8 сәгатькә калдыру таләбе белән митингка чыга. Тагын 3 елдан Париж конгрессы бу датаны Хезмәтчәннәрнең бөтендөнья теләктәшлеге көне дип атый. Русия империясендә ул беренче тапкыр 1890 елда Варшавада (империя составында булган Польша башкаласында) билгеләп үтелә, соңрак Петербург, Мәскәү кушылып китә. Большевиклар чорында бу көн бәйрәм төсе ала, демонстрацияләр үткәрелә. Совет чорыннан соң аның идеологик мәгънәсе югалды, әлбәттә. Ә соңгы тантаналы парад 1990 елда үтте.*

*Хәзер инде 1 май Яз һәм хезмәт көне буларак билгеләнә. Шулай да котлауларда әле булса "Тынычлык! Хезмәт! Май!" дигән язулар яшәп килә. Тагын бер кат Бәйрәм белән!*

## *Май ае*

Каршы алып Май аен
Яфрагын ярган каен.
Шытып чыккан үләннәр,
Яшелеккә күмгәннәр.
Беренче Май бәйрәме,
Кулда чәчәк бәйләме!
Йөрәкләрдә бер теләк-
Тынычлык илгә кирәк!.

Еламасын аналар,
Югалмасын балалар.!
Сугыш уты янмасын,
Бала ятим калмасын!
Диеп кабатлый ана,
Сүзе җилгә тарала.

Кошлар отып алганнар,
Сүзне җырга салганнар,
Нинди матур Җир шары!
Бармы шундый җир
тагы?!
Кояш нуры иркәли,
Ләйсән яңгыр сибәли.

# Бөек Җиңүгә 80 ел




### Онытмыйк Җиңү көнен

Кырык бернең 22 июнь
Илебездә таң атты
Сызгырып төшкән бомбалар,
Халкыбызны уятты.
Фашист илбасарлары,
Басып керде илебезгә.
Туплар шартлап, самолетлар,
Очты тыныч күгебездә.
Күпме кайгы, күпме хәсрәт,
Безгә Гитлер китерде.
Туптан атып,бомба бәреп,
Шәһәрләрне җимерде.
Бөтен халык күтәрелде,
Сакларга, — дип илебезне.
Яше-карты, Һәммәсе дә,
Безнең туган җиребезне.

Фронтовикларыбыз көрәште,
Аямыйча үзләрен.
Ант иттеләр җиңелмәскә,
Үтәделәр сүзләрен.
Ә тылдагы хатын-кызлар,
Әби-бабай, балалар.
Үтәделәр өчәр норма,
Көне-төне дә алар.
Бергәләшеп көрәшүләр,
Безгә җиңү китерде.
Кырык бишнең 9 нчы май,
Илбасарлар җиңелде.
Тугызынчы май, бәйрәм көн.
Җиңү көне ул безнең.
Каршы алыйк, онытмыйча,
Һәрбер елын ул көннең.

9 Май – илебез тарихында һәм Россиянең һәр гаиләсе тормышында мөһим һәм онытылмас дата. Без үзебезне бердәм һәм көчле халык итеп тойган башка мондый көн юк. Бөек Ватан сугышы – ул безнең уртак кайгыбыз, ә Бөек Җиңү – уртак шатлыгыбыз.
Сугыш юлларының һәм сынауларының исәбе-хисабы юк. Бу көнне якынайту өчен солдатлар яуга күтәрелгән. Тылда аналар, хатын-кызлар һәм балалар көч җитмәстәй авыр хезмәт башкарган. Һәм бүген, дистәләгән еллар үткәч, без аларның һәркайсының батырлыгы алдында баш иябез. Сугыш кырларында ятып калган, лагерьларда җәфа чиккән, ачлыктан һәм каты яралардан һәлак булган, Туган ил бөтенлеге һәм бәйсезлеге, халыкларның тормышка хокуклары өчен гомерләрен биргән кешеләрнең барысын да искә алабыз.
Бу якты һәм матур май бәйрәме һәркайсыбыз өчен горурлык чыганагы булсын, йөрәкләребезне шатлыкка күмсен, яшәргә дәрт һәм туган ягыбыз иминлеге өчен эшләргә көч бирсен! Ак бәхетләр, аяз күк йөзе, күңелләрегезгә җылылык һәм гаиләләрегезгә иминлек телибез.
Бүгенге көндә Ватаныбызны саклап көрәшкән ир-егетләребезнең исән-имин әйләнеп кайтуларын,гаиләләренең аларны сөенеп каршы алуларын телибез.





### Авылдашларыбыз- илнең каһарман уллары

Безнең Өчиле җирлегенә 5 авыл керә: Өчиле, Югары Бирәзә, Күкчә-Бирәзә, Иске –Йорт, Чиканас авыллары. Бөек Ватан сугышы башлануга, якташларыбыз илебез өчен барган аяусыз көрәшкә күтәрелә. Ир-егетләр сугышка, бабайлар, әбиләр, хатын-кызлар, бала-чага тылдагы хезмәткә керешә.
Сугышка 5 авылдан 461 ир-егет китә.
Чиканас авылыннан: 112 кеше китә, 84 кеше яу кырында ятып кала, 28 кеше әйләнеп кайта.
Өчиле авылыннан: 74 кеше китә, 49 кеше һәлак була, 25 е исән – имин кайта.
Иске Йорт авылыннан 111 кешенең 40 ы үлеп кала, 71 е кайта.
Югары Бирәзәдән 79 кеше китә ,61 е ятып кала, 18 кеше кайта.
Күкчә-Бирәзәдән 85 кеше сугышка китә. 25 е исән кайта, 60 ы сугыш кырында ятып кала.
Кызганыч, бүгенге көндә җирлегебездә бер сугыш ветераны да калмады инде.
Һәлак булган, хәбәрсез югалган авылдашларыбыз истәлегенә һәр авылда һәйкәлләр куелган. Авыл халкы аларны карап,чистартып тора.

# *Кыңгыраулы мәктәп еллары...*





Тиздән, бик тиздән һәр мәктәптә соңгы кыңгырау чыңлаячак. Бу кыңгырау - укучыларны җәйге ялга, ә чыгарылыш сыйныф укучыларын олы тормыш юлына озатучы.
Җәйге ялларыбыз хәвеф-хәтәрсез, күңелле үтсен!
Ә чыгарылыш укучыларыбыз, сезгә имтиханнарыгызны уңышлы биреп, кулларыгызга аттестат алып, үзегез теләгән уку йортларына керүегезне телибез. Юлларыгыз уң булсын!

Уңышлар Сезгә!


Мәктәп, мәктәп... һәр кеше өчен дә кадерле, изге булган сүзләрдер бу. Чөнки бу тормышта һәркем «мәктәп» дигән олы тормыш баскычын уза. Балалык, яшүсмер еллары, беренче тәҗрибә туплау да мәктәптә уку чорына туры килә. Ул елларны күңелле һәм нәтиҗәле итеп үткәргән кешеләр олы тормыш юлына аяк баскач та югалып калмый, үз сукмакларын, үз юлларын таба ала. Чөнки мәктәптә алынган белем һәм тәрбия балага гомерлек юлдаш, маяк, нигез ташы була...

Мәктәп җырларда җырлана, поэзия,прозада да урыны киң аның. Ә мәзәкләр...Мәзәксез мәктәп мәктәпме инде ул!

*Укытучы:*
*-Вәли, дәресеңә әйтә әле. Кем булышты өй эшен эшләргә?*
*Вәли:*
*-Белмим, мин йоклаган идем.*

*Бер малай мәктәптән өенә кайтып керә:*
*– Җитте! Бүтән бу мәктәбегезгә ике аягымның берсен дә атламыйм!*
*– Нишләп?*
*– Укый белмим, яза белмим, ә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмиләр.*

*Әби оныгы белән мәктәп-мәктәп уйнадылар. Соңыннан гына әби оныгы урынына дәрес әзерләгәнен абайлап алды.*



**Тәүлек буе йокламагыз!**

**Спорт белән шөгыльләнегез!**

**Китаплар укыгыз яки тыңлагыз!**

**Яңа белем-күнекмәләр үзләштерегез!**

**Җәйге ялга алтын киңәшләр**

**Көн саен тышта, саф һавада йөрегез!**

**Әллә кайчаннан ниятләп йөргән эшне башлагыз!**

**Йорт эшләрендә булышыгыз!**

**Куркынычсызлык кагыйдәләрен исегездән чыгармагыз!**